# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“14” ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, 2023 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Таш-Чишмә торак пункты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, үләннәр чабу, транспорт хезмәтләре һәм эш өчен түләү);
2) “Ташчишмә” чишмәсен төзекләндерү (материал сатып алу, эш һәм хезмәтләр күрсәтүләргә түләү);
3) Таш-Чишмә торак пунктының урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыенның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 255 (ике йөз илле биш) кеше кертелгән, ике этапта узган җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 134 (йөз утыз дүрт) кеше, бу 52,55 % тәшкил итә..
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 134 (йөз утыз дүрт) кеше тавыш бирде;
“Юк” позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип таныргa.
2. “Сез 2024 елда Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә,

көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Таш-Чишмә торак пункты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, үләннәр чабу, транспорт хезмәтләре һәм эш өчен түләү);

2) “Ташчишмә” чишмәсен төзекләндерү (материал сатып алу, эш һәм хезмәтләр күрсәтүләргә түләү);

3) Таш-Чишмә торак пунктының урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү).– мәсьәләсен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.